Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«31» гыйнвар, 2024 ел

№ 54

«2024 елга Питрәч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия утырышларын үткәрү графигын раслау турында»

2024 елга юл хәрәкәте иминлеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм алардан килгән зыяннарны киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 17 декабрендәге 1250 номерлы карарын үтәү нигезендә, Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Питрәч муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия утырышларын 2024 елга уздыру графигын (алга таба - программа) расларга.
2. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия утырышларын үткәрү графигын үтәү буенча Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновны билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (https://pestreci.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе

В.И.Никитин